КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 сентябрь г.Казань № 834

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карарына үзгәрешләр кертү турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар системасын эшләү турында» 2006 ел, 16 июнь, 310 нчы карары үз көчен югалткан дип санау хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 ел, 2 ноябрь, 880 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 23 ноябрь, 961 нче; 2012 ел, 15 май, 378 нче; 2014 ел, 11 июнь, 398 нче; 2014 ел, 27 ноябрь, 920 нче; 2015 ел, 17 апрель, 259 нчы; 2015 ел, 14 декабрь, 946 нчы; 2018 ел, 24 июль, 593 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

түбәндәге эчтәлекле $3^1$ нче һәм $3^2$ нче пунктлар өстәргә:

«3[1]. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесен Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләүне методик яктан тәэмин итүне һәм аларга экспертиза ясауны гамәлгә ашырырга вәкаләтле оешма (алга таба – вәкаләтле оешма) итеп билгеләргә.

3[2]. Физик һәм юридик затларга дәүләт хезмәтләре күрсәтүче Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына административ регламентларны Тәртип нигезендә эшләүне, раслауны һәм актуальләштерүне, шулай ук административ регламентларны, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы карары белән расланган «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасы турындагы нигезләмә таянып, «Татарстан Республикасының дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасына кертүне тәэмин итәргә.»;

4 нче пункт үз көчен югалткан дип санарга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтү буенча административ регламентлар системасын эшләү турында» 2006 ел, 16 июнь, 310 нчы карары үз көчен югалткан дип санарга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин